КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 сентябрь г.Казань № 841

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында» 2016 ел, 17 август, 569 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында» 2016 ел, 17 август, 569 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 25 гыйнвар, 37 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турындагы нигезләмәнең 7 нче пунктындагы алтынчы абзацында «СНИЛС» сүзен «шәхси (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ» сүзләренә алыштырырга:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия бирү комиссиясе составында:

Комиссия составыннан Н.Д.Пивоварованы, А.Л.Рыковны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

«Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, комиссиянең җаваплы секретары Тимур Ренат улы Камалетдиновны;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының гражданлык патриотизмын һәм профилактика эшен үстерү бүлекчәсе мөдире Станислав Олегович Каракуловны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин